| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 27 март г.Казань № 176

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 22 февраль, 110 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 30 декабрь, 1063 нче; 2015 ел, 8 май, 333 нче; 2015 ел, 17 июнь, 444 нче; 2015 ел, 30 ноябрь, 906 нчы; 2016 ел, 30 март, 181 нче; 2016 ел, 25 май, 349 нчы; 2016 ел, 13 сентябрь, 640 нчы; 2016 ел, 21 сентябрь, 670 нче; 2016 ел, 28 ноябрь, 877 нче; 2017 ел, 25 гыйнвар, 29 нчы; 2017 ел, 28 апрель, 254 нче; 2017 ел, 26 июнь, 430 нчы; 2017 ел, 12 август, 568 нче; 2017 ел, 6 октябрь, 766 нчы; 2017 ел, 11 декабрь, 967 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасына (алга таба – Программа) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа паспортының «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Програм- | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка |

| | |
|---|---|
| маны финанслау күләмнәре | ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 269 117 289,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:<br>2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,30 мең сум);<br>2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);<br>2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);<br>2017 ел – 44 694 327,93 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 573 598,43 мең сум);<br>2018 ел – 42 092 118,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 9 960 996,1 мең сум);<br>2019 ел – 40 679 242,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 910 996,1 мең сум);<br>2020 ел – 28 014 425,7 мең сум.<br>2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

Программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәре 269 117 289,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән түбәндәге еллар буенча:

2014 ел – 30 831 624,92 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 3 276 380,30 мең сум);

2015 ел – 40 434 999,8 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 10 287 192,8 мең сум);

2016 ел – 42 370 549,4 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 319 020,9 мең сум);

2017 ел – 44 694 327,93 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 12 573 598,43 мең сум);

2018 ел – 42 092 118,9 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 9 960 996,1 мең сум);

2019 ел – 40 679 242,6 мең сум (шул исәптән капитал салуларга – 8 910 996,1 мең сум);

2020 ел – 28 014 425,7 мең сум.

2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Программага 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә);

«2014 – 2025 елларга белем бирү сыйфатын бәяләү системасын үстерү» ярдәмче программасында:

ярдәмче программа паспортында:

«Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Ярдәмче программаны еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, финанслау күләме | Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 717 950,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2014 ел – 92 476,45 мең сум;<br>2015 ел – 86 119,2 мең сум;<br>2016 ел – 93 902,1 мең сум;<br>2017 ел – 174 622,7 мең сум;<br>2018 ел – 137 852,5 мең сум;<br>2019 ел – 66 352,8 мең сум;<br>2020 ел – 66 624,5 мең сум.<br>2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»; |

«Ярдәмче программа максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары)» юлында:

җиденче абзацны төшереп калдырырга;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Россия Федерациясе субъектларының гомуми күләмендә мәктәпкәчә белем, башлангыч гоммуи, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең сыйфатын бәяләүнең төбәк системалары булдырылган һәм эшләп килә торган субъектлар өлеше 2018 елда кимендә 1,18 процент»;

Ярдәмче программаның 2 бүлегендә:

5 нче пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Балаларга мәктәптә белем бирү сыйфатын бәяләү механизмнарын тормышка ашыру (шул исәптән «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә белем бирү сыйфатын бәяләү һәм тәэмин итү механизмнарын тормышка ашыру»;

илле сигезенче абзацта:

«5.1» саннарын төшереп калдырырга;

«2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программаның» дигән сүзләрне «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының» дигән сүзләргә алмаштырырга;

таблица исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1 нче таблица

«2016 – 2020 елларга мәгарифне үстерү федераль максатчан программаның 2017 елда 5.1 «Пилот төбәк проектларын тормышка ашыру һәм сыйфатны бәяләүнең илкүләм механизмнарын булдыру аша гомуми белем сыйфатын бәйсез бәяләү илкүләм-төбәк системасын үстерү» чарасының көтелгән нәтиҗәләре»;

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 2 нче таблица өстәргә:

«2 нче таблица

2018 елда «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә белем бирү сыйфатын бәяләү һәм тәэмин итү механизмнарын тормышка ашыру»;.

| Чара исеме | Чара юнәлеше (Россия Федерациясенең аерым субъектына – субсидия алучыга карата) | Россия Федерациясе субъекты тәкъдиме |
|---|---|---|
| «Дәүләт мәгариф стандартлары нигезендә белем бирү сыйфатын бәяләү һәм тәэмин итү механизмнарын тормышка ашыру» | 1) Имтихан үткәрү пунктларын җиһазлау өчен җайланмалар сатып алу (алга таба – ИҮП) | «ИҮПда тикшерү-үлчәү материалларын басты-ру» технологиясеннән файдалану өчен җай-ланмалар белән җиһаз-ландырылган ИҮП өлешен арттыру |
| | 2) Татарстан Республикасының гомуми белем бирү оешма-ларында төп һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укучыларның белем сыйфатларын бәяләү һәм ирешелгән белемнәре дәрәҗәсен диагностикалау процедура-ларын үткәрү | Рус теле һәм математика буенча «5» билгесе алган ТДИда катнашу-чылар өлешенә мөнә-сәбәттә база дәрәҗә-сендәге рус теленнән кимендә 75 балл һәм математикадан «5» бил-гесе алган БДИ кат-нашучылары өлеше төрлелеген кимету |
| | 3) Мәгариф оешмаларында белем бирү процессын камил-ләштерү өчен БДИ, ТДИ, Бөтенроссия тикшерү эше (алга таба – БТЭ), бүтән бәяләүче процедуралар нәтиҗәләрен фай-далану буенча өйрәтүче чаралар үткәрү | Өйрәүче 5 чара |
| | 4) БДИ, ТДИ, БТЭ үткәргәндә күзәтүчеләр сыйфатында җәлеп ителә торган затлар өчен өйрәтү | Өйрәүче 13 чара |

| | | |
|---|---|---|
| | чаралары үткәрү | |

Ярдәмче программаның 3 бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3. Ярдәмче программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү**

Федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Ярдәмче программа чараларын финанслау күләме 717 950,25 мең сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2014 ел – 92 476,45 мең сум;
2015 ел – 86 119,2 мең сум;
2016 ел – 93 902,1 мең сум;
2017 ел – 174 622,7 мең сум;
2018 ел – 137 852,5 мең сум;
2019 ел – 66 352,8 мең сум;
2020 ел – 66 624,5 мең сум.

2021 – 2025 елларга акча күләме тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән билгеләнә.»;

Ярдәмче программаның 5 бүлегендәге таблицада:
2 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;
таблицага түбәндәге эчтәлекле 21 нче пункт өстәргә:

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «21. | Россия Федерациясе субъектларының гомуми күләмендә мәктәпкәчә белем, башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белемнең сыйфатын бәяләүнең төбәк системалары булдырылган һәм эшләп килә торган субъектлар өлеше | - | - | - | - | 1,18 | - | - | - | - | - | - | -»; |

Ярдәмче программага теркәлгән 1 нче кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин